АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2020 № 333

п.г.т. Алексеевское

**Үз көчен югалткан дип тану турында**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына вазыйфаи затларның аерым категорияләренең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 07 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 пунктының 3 пунктчасындагы «б» абзацын үтәү йөзеннән

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрне яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы карары үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Совет рәисе урынбасары Г.В. Беловага йөкләргә.

**Глава Алексеевского**
**муниципального района,**
**председатель Совета** **С.А. Демидов**